КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 август г.Казань № 1028

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты коллегиясе составын раслау турында» 2016 ел, 09 август, 544 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты коллегиясе составын раслау турында» 2016 ел, 9 август, 544 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 24 октябрь, 773 нче; 2016 ел, 21 декабрь, 964 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1106 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 473 нче; 2020 ел, 16 декабрь, 1139 нчы; 2022 ел, 21 февраль, 149 нчы, 2023 ел, 27 гыйнвар, 58 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составыннан Р.М.Шакирҗановны, А.Д.Шәмсиевны чыгарырга;

коллегия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Гыйләҗев Искәндәр Аяз улын | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең төбәкләрне өйрәнү һәм татар энциклопедиясе институты» аерымланган структур бүлекчәсе директорын, Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының Архив эше буенча иҗтимагый советы рәисен (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Шәрәфетдинов Рәис Мифтах улын | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының эшләр идарәчесен; |

Вафин Эдуард Яфәс улы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин